**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Карасу авыл җирлеге Советы**

**Карар**

№ 43

09.02 .2018ел

**Карасу авыл җирлеге Советы башлыгының 2017 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабы**

Карасу авыл җирлеге Советы башлыгының социаль нәтиҗәләр буенча хисабын тыңлап һәм фикер алышып – 2017 елда җирлекнең икътисади үсеше һәм 2018 елга фараз турында авыл җирлеге советы 2017 елда җирлек халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җирлек халкы мәнфәгатьләрендә эшләр башкарылган дип саный Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы карасы авыл җирлеге Советы:

1. Карасу авыл җирлеге Советы башлыгы Идиятуллин Фәнгать Хәбиб улы 2017 елда авыл җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисапны игътибарга алырга.
2. 2018 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.
4. Кредитлау һәм торак төзелеше өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган программаларның мөмкинлекләрен авылда яшьләрне ныгыту өчен максималь файдалану.
5. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
6. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
7. Торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.
8. Авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
9. Авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.
10. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http:aksubaevo.tatarstan.ru.
11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны карасы авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>
Аксубай муниципаль районы<br>
Карасу авыл җирлеге башлыгы<br>
Совет рәисе:

Ф.Х.Идиятуллин